**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлеге составына керүче Суык-Чишмә авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында Карар**

**18 декабрь 2021 ел № 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 2022 елда үзара салым кертүгә 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме мәсьәләсе буенча 2021 елның 11 декабрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү күз алдында тотыла:
- Суык-Чишмә авылы зиратын төзекләндерү өчен.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 54 кеше, тавыш бирүдә катнашкан 39 кеше теркәлгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
«Әйе» позициясе өчен җыенда 39 кеше тавыш бирде;
«юк» позициясе өчен - җыенда катнашучылар-0;
халык җыенында катнашучыларның 0-се тыелып калды.

Бәян ителгәннәр нигезендә, **халык җыены карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлеге составына керүче Суык-Чишмә авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Татар Димскәе авыл җирлеге Татар Димскәе авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм анда катнашучыларның тол хатыннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, күп балалы гаиләләрдән тыш, 2022 елда Суык –Чишмә зиратын үзара салым кертергә 300 (өч йөз) сум күләмендә килешәсезме дигән сорау буенча карар кабул ителде дип санарга.

2022 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Суык-Чишмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзсалым кертергә.

3. Әлеге карарны Татар Димскәе авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Интернет" челтәрендә рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә. http://bugulma.tatar.ru - "авыл җирлекләре"бүлегенең "татар Димскәсе авыл җирлеге" бүлекчәсе;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Татар Димскәе авыл җирлеге башлыгы Л. А. Хәбирова**